# КОРСАК

Фазыл әфәнде уяныр китте. Тәрәзәнең пәрдәсе араларыннан кояшның нуры бик матур булып озаеп-сузылып мичнең бер почмагын яктыртыбрак тора иде. Күрше бүлмәдә асрауның чыш-чыш кына, акрын гына идән себерүе ишетелеп, Фазыл әфәнденең әллә кайвакытларын искә төшерә иде. Аның уе үзенең бүгенге көндә зур китап магазины хуҗасы вә шактый халык арасында сатыла торган гәзитә мөхәррире булуыннан башлап, акыртын гына артка таба ага башлады. Менә аның күзе алдына үзенең гәзитә чыгара башлаулары, гәзитәне, заманасына муафикъ иттереп, ачык, тугры язуның кирәклеген белсә дә, вөҗданы һәрвакыт шуны теләсә дә, үзенең бай дустларының күңелен сындырмас өчен, гәзитәсен «ак гәзитә» итеп чыгарулары, шуның өчен аны тәнкыйть кыла, сүгә башлаган яшьләргә вөҗданы бер җавап та таба алмаса да, каты-каты сүзләр берлән алардан көләргә мәҗбүр булулары, вөҗданының тавышына һич илтифатсыз, һаман гәзитәдә «итагать», «миссионерларга җавап» кебек, халыкны йоклатып, халыкка һичбер файдалы нәрсә бирмәенчә, халыкның наданлыгын шул гәзитәдә матур иттереп күрсәтеп, акча җыярга гына караулары исенә төште. Вөҗданы тагы уянып китеп, үзенең шул эшенә җавап сорый башлады. Әүвәлдә: «Мин ул вакытта обеспечен түгел идем, җәмәгатем бар иде, аларны карау, аларны тәрбия кылыр өчен мин халыкның яткан ягына йонын сыйпап, акчасын алырга мәҗбүр булдым, бу бер дә гаеп түгел»,—дип уйлады. Бу соңгы сүзенә үзе дә ышанмаганга булырга кирәк, соңгы җөмләсен кычкырып әйтеп йибәрде.

Кылт итеп: «Ник соң хәзер гәзитәне яхшылатмыйм?» — сөале хәтеренә килде. Монысына җавап таба алмаенча шактый гына торды. Үзенең гәзитәсенең, бигрәк үзенең мәкаләләренең бик начар, мотлак ялган, надан халыкны алдап акча алудан башкага ярарлык булмавы күз алдына килә башлады.

Бу ямьсез уйлардан Фазыл әфәнденең әллә кайсы төшләре кычынган кебек булып китте. Ул шул йирне табыр өчен күзен йөртә башлады. Күзе корсагына төште. Корсагы да шактый түгәрәк кенә, йомры гына булган икән. Кылт итеп күңеленә баягы сөальгә җавап та килеп чыкты. «Менә шул корсакның түгәрәклеге өчен гәзитәне шул юлдан алып барам»,— дип җавап бирде. Ләкин вөҗданы, үзенең корсагының түгәрәклеге, якыннарының корсагының туклыгы өчен әллә ничә мең кешенең миен бозып тору бик чирканычлы күренгәнгә, моңарга разый булмады. Вакыйган, бер кешенең корсагының түгәрәклеге өчен әллә ничә мең кешене алдап тор имеш!..

Фазыл әфәнде: «Бусына җавап таба алмасам, минем хезмәтләрем бу гына түгел ич! Әйдә бусы корсак өчен булсын. Минем русчадан тәрҗемә кылган рисаләләрем, тагы, бастырган китапларым? Алар берлән никадәр файда иттем»,—дип уйлады һәм бераз көлеп тә җибәрде. Ул китаплар вә ул рисаләләрнең дә мөхәррирләр тарафыннан халыкны йоклатыр өчен язылган булуы, моның да аларны тәрҗемә кылып, үз халкының татлырак йоклавына гына сәбәп булуы хәтеренә килде.

Моңарда да үзенә хәляс таба алмады. Маңгаен сыйпап җибәреп: «Тагы нишләдем икән?» — дип уйлый башлады.

«Ә, тагы бар! Мөселманнарның җәмгыятьләр ясавына, мөселман иттифакының таралуына хезмәт иттем»,— диде. Ләкин бу җәмгыятьләрнең дә моның вөҗданы каршысында һич файдасы булмавы, шул җәмгыятьләрдән һәрвакыт үзенә гади файданы гына мөляхәзә кылуы, җәмгыятьләр моңарга матди файда ясаудан уза башласа, аңарга каршы төшүләре хәтеренә килде.

Тагы күзе корсагына төште. Тагы вөҗданы: «Корсак!» — дип җавап бирде. Тагы ул элгәреге тормышыннан ялтыраган нөкызләрен эзләргә тотынды. Үзенең иң әүвәл язган, бөтен күңеленнән халыкка файдалы булырга теләп, файдасыз кешеләрне ямьсез сурәттә күрсәткән китабы күз алдына килде. Фазыл әфәнде шатланып китте. Хәтта үзе сизмәенчә дә урынннан селкенеп тә куйды. Хәтеренә ул вакытта корсагының кечкенәрәк булуы, тормышының фәкыйррәк булуы, халыкка хезмәт фикерләре бөтен рухына ләззәт,

тормышына рәхәт бирүләре, үлгәнчә шул юлда хезмәт итәргә вәгъдә кылулары, сәгадәт, рәхәт шул хезмәт юлында гына табыла, дип бик ышанулары, һәрбер файдалы эш күрсә, балалар кебек сөенүләре, һәр начар эшне дошман күреп, һәр начар кешедән халыкны сакларга тырышулары исенә төште. Шул уй берлә, шул иске хатирәләре берлә ләззәтләнә, шатлана башлады. Бу шатлык та озакка бармады. Үзенең ул вакытта көлгән, яратмаган, аларны зарарлы итеп тапкан кешеләрдән моның үзенең хәзер никадәр аермасы барлыгы сөале хәтеренә төште. Вөҗданы тагын: «Алар прастуй кешеләр иде, аларның зарарлары да үзләре кадәр генә иде, аларның игътибарлары да шулкадәр генә иде. Син, шуларның дошманы, халыкның дусты күренеп, игътибар казандың. Аларның тәртипсез сүзләре бәрабәренә үткен каләм берлән, игътибарың аркасында шул халыкны зәһәрли башладың. Алар сүзләрен бер ике-өч кенә кешегә ишеттерәләр иде һәм сүзләре өчен акча алмыйлар иде. Син каләм сайәсендә үзеңнең зарарлы, халыкны йоклата торган сүзләреңне бөтен укучыларга сөйли башладың. Шул агу берлән зәһәрләндекләре өчен алардан акча да алдың. Синең берлән аларның гаепләре җир берлән күк кадәр»,— диде. Фазыл әфәнде: «Ник болай булдым соң?» — дип уйлады. Тагы: «Корсак, корсак!» — дигән җавап хәтеренә килде.

Корсак, корсак! Син берникадәр кешеләрнең тәннәрендә генә түгәрәкләнеп, май берлән капланып торыр өчен миллионнар кешеләрнең тәннәренә корсакларны ябыштырасың! Миллионнар кадәр корсакларын ач калдырасың! Миллионнар кешеләрнең тугры юлдан язып, үзенең туганын, дустын, ишен ач калдыруына сәбәп буласың! Фазыл әфәнде кебек кешеләрнең халыкка файда урынына зарар итүләренә сәбәп буласың! Әй корсак, корсак!

*Гыйнуар, 1909 нчы ел*

## Искәртмәләр һәм аңлатмалар:

*Муафик* — туры килгән.

*Итагать* — буйсыну, карышмау.

*Мотлак* — һичшиксез.

*Вакыйган* — чыннан да.

*Хәляс*— котылу

*Иттифак* —берлек.

*Мөляхәзә* — фикер йөртү

*Нөкыз* — җимерек, ватык.

*Каләм сайәсендә* — каләм ярдәмендә.

*Тәмәркәз* — туплану.

*Истихкар* — түбән күрү, хурлау.

*Истиһза* — көлү, мыскыл итү.

*Мәкамендә* — урынында.

*Хикәяте гаҗибә* — шаккатырырлык хикәя.

*Мөтәүвафа* — үлгән.

**Корсак** —Хикәя беренче тапкыр «Таң» йолдызы гәзитәсенең 1906 ел, 26 май (3) санында басылган. Имза: Корсаксыз. Г.Исхакыйның «Җыентык» (1909) исемле китабына кертелгән.

Хикәянең язылу тарихы шактый кызыклы. 1905 елгы революциядән соң татар лидерлары «таңчылар» һәм «иттифакчылар» төркемнәренә бүленәләр. «Таңчылар»ның идеологлары: Г.Исхакый, Ф.Туктаров, С.Рәмиев, Ш.Мөхөммәдьяров, Х.Әбүзәров, И.Бикчурин, ә «иттифакчылар»ныкы: «Й.Акчура, И.Гаспринский, Г.Тупчыбашев, С.Алкин, Һ.Максуди, Ф.Кәрими, Р.Ибраһимов.

«Таңчылар» сыйнфый көрәшне пропагандалый, алар җәмгыятьне социаль үзгәртеп коруга бары тик революция юлы белән генә ирешергә мөмкин дип чыгалар. «Мөселман итгафакы» тарафдарлары исә милләтне саклап калырга һәм тәрәкькый иттерергә милли-мәдәни мохтариатка ирешү һәм мәгърифәтне үстерү генә ярдәм итәчәк дип саныйлар.

«Таң йолдызы» белән Оренбургта чыга торган «Вакыт» гәзитәләрендә ике партия лидерлары арасында кызу бәхәсләр бара. Г.Исхакыйның «Таң йолдызы»ндагы мәкаләләренең байтак өлеше «иттифакчылар»ны

тәнкыйтьләүгә багышланган. *(Таң йолдызы, 1906 ел, 3, 15, 21 нче августта, 5, 9 нчы сентябрьдә басылган мәкаләләр.)* «Иттифакчылар»ның лидерларыннан Ф.Кәримине тәнкыйтьләп, әдип әлеге «Корсак» исемле сатирик хикәясен яза. Хикәядән соң; «Ошбу укыган хикәяте гаҗибәңезнең савабын «Вакыт» мөхәррире Мөхәммәдфатыйх мелла Гыйлман угылы Кәримовның мәрхүм вә мөтәүвафа рухына багышладыгызмы? Багышладык, багышладык!» — дип язылган.

Моңа җавап итеп, Ф.Кәрими «Корсаклы» псевдонимы белән «Корсак» исемле сатирик хикәясен бастыра (*Вакыт, 1906, 1 июнь).* Хикәядән соң идарәдән мондый сүзләр бирелә: «Һәр нә кадәр гәзитәмез битараф улып, бәхәс вә низагларга урын [бирү] фикерендә түгел исә дә, «Таң йолдызы»ның мәсләке Русия мөселманнарында яңы гына уйганырга башлаган иттихад, иттифак, хәмияте миллия вә динияне тәмам тамырыннан корытудан гыйбарәт улдыгына күрә, биззарур «Корсаклы» әфәнденең мәкаләсене дәреҗ иттек. Вә лөзүми күрелгән тәкъдирдә бу гәзитәнең мәсләкене вә аңарга кемнәрнең вә ни өчен һәм ниндиен косур илә хезмәт итеп, мөселманнарны кайда алып барырга тырышдыклары күрсәтелә торыр».

Г.Исхакый җавабында: «Без «Вакыт»ның «Таң»га дошманлык итеп «Таң»ны язучылар өстеннән жандармериягә мөрәҗәгать кылуында да, аларны халык күзенә динсез итеп күрсәтергә теләвендә дә байлар сыйныфы берлән эшчеләр сыйныфының тартышуын, җиңешүен күрәмез. Без бу тартышулардан бер дә курыкмыймыз. Без бу тартышуларга бик ачык күз белән карап, татар буржуазиясенең эшче һәм авыл халкының гәзитәсе «Таң»га ителгән шул һөҗүменә татар байларының вә байлар тәрилкәсе ялаучыларның татар эшчеләре, татар авыл халкына, татар укыган кешеләренә һөҗүмнәре дип карыймыз. Һәм дә кулымыздагы коралымызны хәзерләп, татар буржуазиясенә каршы ачык тартышуымызда һәрвакыт дәвам итәмез. «Тартышуда гына табарсың син үзеңнең хакыңны!» дигән сүзгә ышанганга, аткан угымызның урынына тиеп, буржуазиянең саклanучысы «вакытчылар»ның шул котыруына бик шатланып, тартышуның билфигыль мәйданга чыгуын күрәмез... Үз

корсагыннан башканы белми торган, корсагы өчен кешеләрдәге бар мөкатдәс нәрсәне корбан кылган мөхәррирләрнең зәһәрләреннән саклап, аларга тугры юл күрсәтү «Таң»чыларның эшедер. (*Чыңгыз.— «Вакыт»ка җавап.— Таң йолдызы, 1906, 9 июнь*).

Чыганак: Исхакый Г. Әсәрләр. 2 том. - Казан:
Татарстан китап нәшрияты, 1999. Б.30-32